

Россия Мәдәният министрлыгында Мордовиядә туган даһи «рус Родены» Степан Дмитриевич Эрьзянын тууына 150 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты утырышы үтте. Алар безнен илдә 2026 елда узачак. Россия мәдәният министры Ольга Любимова рәислегендә узган утырышта Мордовия Главасы Артём Здунов катнашты.       Фикер алышуны ачып, Ольга Любимова ассызыклаганча, Степан Эрьзя исеме – Россия, Европа һәм Латин Америкасы мәдәниятләренен байлыгы. Юбилей чараларын әзерләүгә инде Дәүләт Рус музее һәм Дәүләт Третьяков галереясе кушылды. “Эрьзя исемендәге Мордовия республикасы сынлы сәнгать музее күренекле скульпторнын ижади мирасын саклауда аерым роль уйный һәм илебезнен ин мөһим мәдәни үзәкләренен берсе булып тора. Ә 150 еллык юбилейны бәйрәм итү - һичшиксез, илебезнен бердәм мәдәни кинлеген ныгытуда зур әһәмияткә ия булган масштаблы федераль проект”, - диде Россия мәдәният министры.
Артём Здунов Мордовиядә, Санкт-Петербургта, Мәскәүдә һәм башка төбәкләрдә узачак юбилей чаралары комплексын уздыру концепциясен тәкъдим итте. Республика Главасы билгеләп үткәнчә, Эрьзя скульптураларынын доньядагы ин зур коллекциясе хәзер Мордовиядә 200 дән артык. Утыз елдан артык Мордовия республика сынлы сәнгать музее оста исемен йортә. Юбилей елында «Степан Дмитриевич Эрьзянын 150 еллыгына 150 чара» Ботенроссия проекты эшли башлаячак (әйтеп китәргә кирәк, проект эшли башлады) - бу экскурсияләр, күргәзмәләр, фәнни - гамәли конференцияләр, фестивальләр һәм башкалар. «В рамках работы комиссии Госсовета по направлению «Семья» мы должны придать семейноцентричность всем мероприятиям проекта – чтобы семьи посещали мероприятия и все от мала до велика понимали, о ком идет речь», - дип ассызыклады төбәк житәкчесе.



«Степан Эрьзя – донья скульпторы» күргәзмә проекты оч Россия музеен дуслык һәм ижат жепләре белән тагын да якынайтачак. Рус музее һәм Эрьзя музее коллекцияләреннән шедеврлар кергән күчмә күргәзмә Санкт-Петербургта, Мәскәүдә (Третьяков галереясе) булачак һәм Степан Дмитриевичнын туган конендә, 8 ноябрьдә Саранскига киләчәк. Күргәзмә ачылу конендә барысына да керү бушлай булачак. «Тарихта беренче тапкыр мастер-резчыкнын эшләре Россиянен ин эре музейларында тәкъдим ителәчәк», - дип билгеләде Артём Здунов һәм Ольга Любимованы бу тарихи проектнын Санкт-Петербург, Мәскәү һәм Саранскидагы вернисажларына чакырды. Шулай ук юбилей датасын бәйрәм итү кысаларында Ботенроссия реставрация Советы, Мордовия Республикасында Рус музее коннәре, «Эрьзя в сердце России» уникаль күргәзмә транзиты, Мәскәүдә Россия Сәнгать академиясендә төбәк коне һәм Саранскта Россия Сәнгать академиясе белән берлектә скульптура симпозиумы узачак.
Россия Банкы белән берлектә «Россиянен күренекле шәхесләре» сериясендәге истәлекле комеш тәнкәләр чыгарылачак. Шулай ук мультимедиа проектлары һәм хәтта

Яушев исемендәге опера һәм балет театры труппасы тарафыннан «Эрьзя и время» балетын кую да планлаштырылган. Инде традициягә әйләнгән милли мәдәниятләрнен Ботенроссия яшьләр фестивале 2026 елда исемен «Без Эрьзя белән бергә»гә алыштырачак.



Скульпторнын кече ватанында, Ардатов районынын Баево авылында Тобәкара Милли-фольклор бәйрәме «Шумбрат, Эрьзя!» узачак.
Юбилей датасына әзерлек кысаларында уртак эш турында Рус музее һәм Третьяков галереясе житәкчеләре Алла Манилова белән Елена Проничева сойләгәннәр. Алла Манилова билгеләп vткәнчә, Рус музее десанты Мордовиядә биш кон эшләячәк – реставрация мастер-класслары, пленэрлар һәм музей хезмәткәрләре очен бик кvп башка моһим чаралар узачак. Ул шулай ук РФ Мәдәният министрлыгынын «Россиянен музей маршрутлары» Ботенроссия проекты кысаларында Мордовия патронаты булу инициативасы белән чыгыш ясаган - Республика анда икенче тапкыр катнаша.
С.Д.Эрьзя исемендәге музей директоры Людмила Нарбекова, булачак юбилей вакыйгасына һәм масштаблы кvргәзмәгә комментарий биреп, гениаль скульпторнын ботен сәнгать мирасы беренче тапкыр бер урында – Мордовия Республика сынлы сәнгать музеенда тәкъдим ителәчәген билгеләп vткән.
Без дә музейда булдык: бу чынлап та шулай булачагына инандык. Чонки һәр килv белән музейда, тирә-ягында ниндидер vзгәрешләр барлыкка килә. Торле кvргәзмәләр еш оештырыла, шуларнын берсендә булып кайттык. Ул - Санкт-Петербургтан кvптәнге дус рәссамнары Андрей һәм Николай Дмитренколарнын «Интеллектуаль реализм» кvргәзмәсендә булырга насыйп булды. Әле Анатолий Шведцовнын «Начало» картиналары кvргәзмәсе эшли. Үткән атнада «Эрьзя музеенда гаилә» фотокvргәзмәсе кызыклы булды. Боек Эрьзя Юбилеен лаеклы каршы алачакбыз.

**Наилә НАСЫРОВА**